Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге составына керүче Яңа Чуаш Адамы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2020 елның 09 ноябре № 3

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Емелькино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендәге 100 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегендә 2020 елның 09 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: "2021 елда һәр балигъ булган һәм Аксубай муниципаль районы Емелькиноавыл җирлеге Яңа Чуаш Адамы торак пунктының территориясендә теркәлгән кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә 1 төркем инвалид, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш) һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме?:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- торак пункт чикләрендәге урамнарны кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр өчен түләү);
- вак таш капламлы юл полотносы урнаштыру (вак таш сатып алу, ЩПС; эш өчен түләү - грунт күтәрү, вак таш салу, ЩПС)

2. Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.
- буа ярларын ныгыту ( эшләр өчен түләү);

3.Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:

- контейнер мәйданчыгы төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

ӘЙЕ ЮК ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 198 граждан кертелгән, җыенда катнашучылар саны - 123 граждан.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- "әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 123 кеше тавыш бирде;

- җыенда катнашучы «юк» позициясе өчен 0 кеше тавыш бирде;

- “тыелып калам” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Емелькино авыл җирлеге составына керүче Яңа Чуаш Адамы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-чын мәгънәсендә.

2. "2021 елда һәр балигъ булган һәм Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Яңа Чуаш Адамы торак пунктының территориясендә теркәлгән кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә (1 төркем инвалид, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш) һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән алдагы эшләрне башкару буенча:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- торак пункт чикләрендәге урамнарны кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр өчен түләү);

- вак таш капламлы юл полотносы урнаштыру (вак таш сатып алу, ЩПС; эш өчен түләү - грунт күтәрү, вак таш салу, ЩПС)

2. Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

- буа ярларын ныгыту ( эшләр өчен түләү);

3.Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:

- контейнер мәйданчыгы төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Емелькино авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ игълан итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Аксубай
муниципаль районы Емелькино
авыл җирлеге башлыгы Н.И.Михайлова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕМЕЛЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1603000796 ОГРН 1021605364980